**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **с. Тюлячи** **БОЕРЫК**

«28» февраль **2025ел** **№** 36

2025-2030 еллар чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында туучылар санын арттыру һәм абортлар санын киметү буенча юл картасын (чаралар планын) раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

1. 2025-2030 еллар чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында туучылар санын арттыру һәм абортлар санын киметү буенча юл картасын (чаралар планын) кушымта нигезендә расларга.
2. Муниципаль районның, авыл җирлекләренең, территориаль дәүләт учреждениеләренең җирле үзидарә органнарына, әлеге боерыкның 1 пункты нигезендә, юл картасын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«28» 02 2025 № 36
боерыгына кушымта

**2025-2030 еллар чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында туучылар санын арттыру һәм абортлар санын киметү буенча юл картасын (чаралар планын)**

## I бүлек «Демографик потенциалны бәяләү» (аналитик өлеш)

Туучылар санына муниципаль район (Городская округы) буенча анализ ясарга кирәк, туучылар санына йогынты ясаучы факторларны исәпкә алып, шул исәптән:

- яңа гаилә төзергә ярдәм итә торган шартлар, шул исәптән никахлашканда ир-атлар һәм хатын-кызлар яшьләре;
- яшь төркемнәрендә хатын-кызлар саны:

17-18 яшь - 158,
19-35 яшь - 1308,
36-55 яшь - 1777, шул исәптән, фаразны исәпкә алып, күрсәтелгән төркемнәрдә хатын-кызлар саны;

- хатын-кызларнын яшь төркемнәрендә бала тудыру ешлыгы - тудырулар саны 25-42 яшь төркемендә теркәлә;
- баланың туу чираты буенча ананың урта яшендәге үзгәрешләр - бала табарга теләгән хатын-кызның яше арту тенденциясе бар;
- төрле яшь төркемнәрендә тууга йогынты ясый торган факторлар (25 яшькә кадәр, 25-30 яшь, 30-39 яшь);
- гаиләләрдә тууны кичектерү сәбәпләре, шул исәптән, никахлашканнан соң 1 - 3 ел эчендә ир белән хатын бала табу турында карар кабул итмәү - торак проблемалары;
- ир-атларның һәм хатын-кызларның репродуктив сәламәтлеге торышы һәм ЭКО методына ихтыяж булу - ОМС буенча ЭКО үткәрүгә ихтыяж;
- йөклелекне өзү очракларының сәбәпләре (шул исәптән абортлар), шулай ук йөклелекне алып бару сыйфаты - тотрыклы булмаган хезмәт хакы, торак булмау;
- гаиләләрнең керемнәре структурасы, шул исәптән беренче, икенче һәм аннан соңгы балалар тугач, гаиләләрнең керемнәре дефициты.

ГХАТ Секторы тарафыннан 2024 елда туу турында 46 акт теркәлгән, бу узган елгы дәрәҗәдән 6 язмага күбрәк (2023 ел - 40).

Кызганычка каршы, барлык балалар да тулы гаиләдә тумый. 2024 елда никахтан тыш туган балалар саны 2 (2023 ел - 5) тәшкил итте.

Ата булуны билгеләү турында 11 акт теркәлгән (2023г - 9), ир-ат кеше баланың әнисе ризалыгы белән үзен әтисе дип тануы очрагында. 6 акт баланың тууын теркәү белән бер үк вакытта төзелгән, 4 акт никахлашканнан соң төзелгән, 1 акт ата булуны тану фактын билгеләү турындагы суд карары нигезендә төзелгән.

Гаиләдә икенче һәм аннан соңгы балалар туу социаль тормышның мөһим күрсәткече булып тора, бу районга, республикага, дәүләткә һәм җәмгыятькә тулаем алганда халык санын тотрыкландыруга һәм алдагы үсеш перспективаларына мөмкинлек бирә.

Тууы 2024 елда теркәлгән балаларның гомуми санынннан - 138. Алар арасыннан 86 бала ДАССУ «Теләче үзәк район хастаханәсе» нә беркетелгән. 2 гаиләнең игезәкләре туды.

2024 елда районда 45 пар язылышкан, бу узган ел белән чагыштырганда 17 парга кимрәк (2023 ел - 62 пар).

Никахлашучылар арасыннан:

30 пар кабат өйләнешә (ир-атлар - 14, хатын-кызлар - 16).

1 милләтара никах.

Иң өлкән кияүгә 56 яшь һәм кәләшкә 48 яшь.

Аерылышу 2024 елда - 59 (2023 елда - 53 аерылышу).

Яше буенча иң өлкәне эти 2024 елда - 51 яшь, иң өлкән әни - 42 яшь.

Иң яшь эти - 24 яшь, иң яшь әни - 18 яшь.

Соңгы 5 елда район буенча яше кимегән пар саны юк.

**Хатын-кызларның яшь төркемнәрендә туу ешлыгы**

| Яшь төркемнәр | 2025 ел |
| --- | --- |
| 18-25 | 22 |
| 26-30 | 22 |
| 31-35 | 21 |
| 36-45 | 11 |
| 40-49 | 18 |

**II бүлек. «2025-2030 еллар чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында туучылар санын арттыру һәм абортлар санын киметү буенча юл картасының (чаралар планын) максатчан күрсәткечләре»**

| № т/б | Максатчан күрсәткеч исеме | База төшенчәсе | | Фараз | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел |
| 1. | Репродуктив яшьтәге хатын-кызлар саны (15-49 яшь), кеше | 2815 | 2745 . | 2737 | 2726 | 2726 | 2720 | 2711 | 2709 |
| 2. | Туучылар саны, кеше | 131 | 138 | 123 | 125 | 125 | 125 | 130 | 130 |
| 3. | Еллар буенча чагыштыруда туучылар санының кимү/артуы процентлары, % | 4,8 22 ел - 125 | 5,3 | -10,8 | -9,4 | -9,4 | -9,4 | -5,7 | -5,7 |
| 4. | Йөклелекне өзү саны, очраклар | 21 | 7 | 6 | 6 | 5 | 5 | 5 | 5 |
| 5. | Туучылар санының суммар коэффициенты, 1 хатын-кызга туучылар саны | 0,046 | 0,050 | 0,044 | 0,045 | 0,045 | 0,045 | 0,047 | 0,047 |
| 6. | Халык саны, кеше | 13368 | 13214 | 13127 | 13120 | 13110 | 13100 | 12998 | 12900 |

**Раздел III. «2025-2030 еллар чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында туучылар санын арттыру һәм абортлар санын киметү буенча юл картасы (чаралар планы)»**

| № т/б | Чараның атамасы | Җаваплы башкаручылар | Гамәлгә ашыра башлау срогы | Гамәлгә ашыруны тәмамлау срогы | Көтелгән нәтиҗәләр (нәтиҗәнең исеме һәм сан күрсәткечләре) | Туучылар санын бәяләү (кеше) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| **1. Репродуктив сәламәтлекне ныгыту һәм абортлар санын кыскарту** | | | | | | |
| 1.1. | Репродуктив яшьтәге ир-атларны һәм хатын-кызларны диспансерлаштыру чараларын гамәлгә ашыру | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Бала таба алмау фактын, шулай ук репродуктив система авыруларын иртәрәк ачыклау | Арту |
| 1.2. | Югары кискен хәл төркемендәге йөкле хатын-кызларны вакытында ачыклау һәм әлеге | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Сакланган йөклелекне арттыру | Арту |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | төркем хатын-кызларны, дәвалау программаларын алга таба үтәп, тикшерүне тәэмин итү | | | | | |
| 1.3 | Балигъ булмаганнарга, дәвалау программаларын үтәп, тайпылышларны иртә ачыклау максатында, медицина профилактикасын үткәрү | ДАССУ «Теләче РҮХ» | Даими рәвештә | Даими рәвештә | Авыруларны алдан ачыклау, вакытында тикшерү һәм дәвалау, шулай ук профилактик чаралар хатын-кызларның репродуктив сәламәтлеген саклап калырга мөмкинлек бирәчәк | |
| 1.4 | Абортларны профилактикалау һәм йөклелекне планлаштыру буенча мәгълүмати агарту чаралары үткәрү | ДАССУ «Теләче РҮХ» | Даими рәвештә | Даими рәвештә | Чараларда катнашкан хатын-кызлар өлеше, гомумән алганда, фертиль яшьтәге хатын-кызлар санында | |
| 1.5 | Хроник авырулардан интегүче авырлы хатын-кызларны шифаханә-курорт дәвалауны тәэмин итү | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Репродуктив югалтулар дәрәҗәсенең кимүе,<br>2025 ел - 100%<br>2026 ел - 100%<br>2027 ел - 100%<br>2028 ел - 100%<br>2029 ел - 100%<br>2030 ел - 100% | |
| 1.6 | Экстракорпораль аталандыру ысулларын куллану мөмкинлеге мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Туучылар санын 2025 елда-100%ка арттыру<br>2026 ел - 100%<br>2027 ел - 100%<br>2028 ел-100%<br>2029 ел - 100%<br>2030 ел - 100% | |
| 1.7 | Йөклелекне өзү уңаеннан медицина учреждениесенә | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Фертиль яшьтәге 1 мең хатын-кызга абортлар күрсәткеченең | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | мөрәҗәгать иткән хатын-кызлар белән шәхси әңгәмәләр | | | | кимүе | |
| 1.8 | Йөкле хатын-кызларны өстәмә тимер препаратлары һәм витаминнар белән тәэмин итү | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |
| 1.9 | Балаларын тәрбияләүгә намуслы караучы, балаларының сәламәтлеге, белеме, физик, рухи һәм әхлакый үсеше, аларның шәхесенең тулы һәм гармонияле үсеше турында тиешле дәрәҗәдә кайгыртуны тәэмин итүче, балаларны тәрбияләүдә үрнәк булып торучы күпбалалы аналарны бүләкләү, «Материнская Слава - Ана даны», «Родительская доблесть» медальләрен тапшыру | МТЗ һәм КЦСОН «Родник», Теләче МРда ТР социаль яклау бүлеге, ГХАТ секторы | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |
| 1.10 | Мәктәп укучылары һәм студентлар арасында абортның зарары һәм җенес акты кагыйдәләре турында лекцияләр үткәрү | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 01.01.2025 Елга 2 тапкыр | 31.12.2030 Календарь ел дәвамында | Яшүсмерләрдә теләмәгән йөклелек һәм абортлар булмау | |
| **2. Балалы гаиләләргә ярдәм** | | | | | | |
| 2.1 | 4 һәм аннан күбрәк баласы булган, 18 яшькә кадәрге, районның гомуми белем бирү оешмаларында 5-11 сыйныфларда белем алучы күпбалалы гаиләләрдәге балаларны бушлай тукландыру | МКУ «Мәгариф бүлеге» | 01.01.2023 | 31.12.2030 | 5-11 сыйныфларда белем алучы балаларны бушлай тукландыру | 100 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2 | Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Теләче муниципаль районы белем бирү оешмаларында караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итү | ТМР башкарма комитеты | 01.01.2023 | 31.12.2030 | | 100 |
| 2.3 | Күпбалалы гаиләләргә (18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган) мөлкәткә салым ташламаларының 100%ы | ТМР башкарма комитеты | 01.01.2023 | Сроксыз | Күпбалалы гаиләләрне арттыру | |
| **3. Авыл җирендә яшәүче балалары булган гаиләләргә ярдәм** | | | | | | |
| 3.1 | 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарның җир кишәрлекләре белән тәэмин ителеше (%) | МКУ «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Җир кишәрлекләрен бирү | |
| **4. Балаларны тәрбияләүне һәм белем алуны уңышлы берләштерү, һөнәри гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру** | | | | | | |
| 4.1. | Районның балалар мәгариф учреждениеләрендә һәм мәгариф оешмаларында урыннар тәэмин итү | МКУ «Мәгариф бүлеге» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Районның балалар мәгариф учреждениеләрендә һәм мәгариф оешмаларында урыннар тәэмин итү:<br>2025 елда - 100% бала<br>2026 елда - 100% бала;<br>2027 елда - 100% бала;<br>2028 елда - кимендә 130 бала;<br>2029 елда - 100% бала;<br>2030 ел - 100% бала | 100 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **5. Гаилә юнәлешендәге инфраструктураны булдыру һәм торак шартларын яхшыртуда гаиләләргә ярдәм күрсәтү** | | | | | | |
| 5.1 | Торак шартларын яхшырту буенча федераль һәм республика программаларын, шул исәптән яшь гаиләләрнекен, гамәлгә ашыру | ТМР БК инфраструктура үсеше бүлеге | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшырту | |
| **6. Гаилә институтын, шул исәптән күпбуынлы институтны ныгыту, җәмгыятьтә традицион Россия рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен, гаилә яшәү рәвешен саклап калу һәм алга этәрү** | | | | | | |
| 6.1. | ГХАТ секторының гаиләне саклап калу мәсьәләсе буенча үзара килешү буенча никахны өзәргә карар кылган ир белән хатын белән эше | ГХАТ секторы | Даими рәвештә | Ел дәвамында | Аерылышулар саны кимү | |
| 6.2 | «Гаиләгә ярдәм» проекты кысаларында «Яшь ата-ана мәктәбе» чаралары үткәрү | Ак калфак, «Әтиләр берлеге», ГХАТ секторы, «Родник» социаль яклау үзәге, Теләче МРда ТР социаль яклау бүлеге | Ярты елга бер тапкыр | Тулаем чор | Гаиләләр санын арттыру | |
| 6.3 | Гаилә яшәү рәвеше кыйммәтләрен арттыруга юнәлдерелгән социаль әһәмиятле даталарга бәйрәм чаралары үткәрү: Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә, Әниләр көненә, Әтиләр Көненә, Гаилә тормышының юбилярларын хөрмәтләү, спорт бәйрәмнәренә һ.б. | Мәдәният бүлеге, «Мәгариф бүлеге» МКУ Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, «Родник» халыкка социаль ярдәм күрсәтү үзәге, Теләче МРда ТР социаль яклау бүлеге, ГХАТ секторы | Ел саен | Тулаем чор | Гаилә үзәкләрен ныгыту | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.4 | Беренче баланы котлау | ГХАТ секторы | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |
| 6.5 | Елның беренче һәм соңгы парларын котлау | ГХАТ секторы | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |
| 6.6 | Гаилә тормышы юбилярларын котлау | ГХАТ секторы | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |
| 6.7 | Тантаналы рәвештә паспортлар тапшыру | ГХАТ секторы, «Алдынгылар хәрәкәте» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |
| | **7. Башка чаралар** | | | | | |
| 7.1 | Районның социаль челтәрләрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында гаилә кыйммәтләрен пропагандалаучы чараларны яктырту | ТМР Башкарма комитеты, «Теләче» район газетасы редакциясе | даими рәвештә | даими рәвештә | Традицион гаилә кыйммәтләрен һәм актив озак яшәүне алга сөрү һәм популярлаштыру | |
| 7.2 | Физик культура белән шөгыльләнүче гаиләләр өлеше, спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр һәм аларның ата-аналары арасында өлеше арту (%) | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Актив яшәү рәвеше һәм озын гомер популярлыгы | |
| 7.3 | «Дустанә сыйныф серләре» ата-аналар комитетларының республика конкурсында катнашу | МКУ «Мәгариф бүлеге» | 01.01.2025 | 31.12.2030 | Традицион гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру | |
| 7.4 | Ел саен үткәрелә торган «Эхо веков в истории семьи - Тарихта без эзлебез» шәҗәрә фестивалендә катнашу | Архив секторы | 01.01.2025 | 31.12.2030 | | |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев